## Казан шәһәре Башкарма комитетының

2024 елның 29 маендагы 2194 номерлы карары

# Казан шәһәре Идел буе районының Җиңү проспекты буенча ачык сервитут билгеләү турында

1. Әлеге карарга 1 номерлы, 2 номерлы кушымталар нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитут характеристикасы:

- йогынты ясала торган мәйдан – 85 кв.м;

- хокуклары чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры: 16:50:150101:30, 16:50:000000 кадастр кварталының бер өлеше;

- урнашу урыны: Казан шәһәре, Идел буе районы, Җиңү проспекты;

- билгеләү максаты: ТП-2907 җирле әһәмияттәге трансформатор подстанциясе электр челтәре хуҗалыгы объектын урнаштыру;

- билгеләү вакыты: 49 ел;

1.2. гариза бирүче: «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте;

1.3. билгеләү өчен нигезләр: гариза бирүче мөрәҗәгате, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясы, 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында»гы федераль законның 3.6 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы «Электр челтәре хуҗалыгы объектларының сак зоналарын билгеләү тәртибе һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым шартлары турында»гы карары (2018 елның 21 декабрендәге редакциядә), Казан шәһәре Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округының Генераль планы, җирле әһәмияттәге ТП-2510-16 трансформатор подстанциясенә милек хокукы теркәлгән (2008 елның 14 апрелендәге 16-16-01/062/2008-503 номерлы).

2. Әлеге карарга 1 номерлы һәм 2 номерлы кушымталарда күрсәтелгән җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаячак яисә сизелерлек кыенлашачак вакыт әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут вакытына туры килә дип билгеләргә.

3. «Шәһәрне үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарга 1 номерлы, 2 номерлы кушымталар нигезендә чикләрдә ачык сервитутның гамәлдә булу өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итәргә.

4. Әлеге карарга 2 номерлы кушымтадан кала (хезмәт урынында файдалану өчен материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм баш-

ка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.


6. «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенә әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлеген, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яисә агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, консервацияләү, сүтү эшләре тәмамланганнан соң яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктларында каралган максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлегендә тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң, өч айдан да соңга калмыйча, аннан рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерергә тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 29 маендагы
2194 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Җир кишәрлегенең бер өлешенә һәм кадастр кварталының бер өлешенә ачык сервитут йогынтысы булган чикләр**




| | |
|---|---|
| Масштаб 1:100<br>Координаталар системасы: МСК-16 | |
| Шартлы билгеләр: | |
| 1 | яңа барлыкка килгән характерлы нокта |
| | билгеләнә торган сервитут чиге |
| | гамәлдәге җир кишәрлекләре чиге |
| | территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган (гамәлдәге) |
| | кызыл линияләр (гамәлдәге) |
| | капиталь төзелеш объектлары (мәйданлы) |
| 16:50:150101 | кадастр кварталы |
| 16:50:150101:30 | хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |